МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.05.2022 Казан ш. № 07-56

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләре реестрларын тапшыру тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 87 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләре реестрларын тапшыру тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләре реестрлары җыентыкларын тапшыру тәртибе турында” 12.10.2007 ел, № 07-81 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Г.Ю. Герасимовага йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
11.05.2022 № 07-56
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләре реестрларын тапшыру тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы шәһәр округларының чыгым йөкләмәләре реестрын, Татарстан Республикасы муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләре реестрын һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнар составына керүче җирлекләрнең чыгым йөкләмәләре реестрлары җыелмасын (алга таба – РО МО реестрлары) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру процедурасын һәм срокларын билгели.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының финанс органнары (алга таба – финанс органнары) һәр ел саен, агымдагы финанс елының 10 маеннан да соңга калмыйча, Министрлыкка Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 3 март, 2020 ел, №34н боерыгы белән расланган формалар буенча, "БАРС Web-Своды" программасында электрон документлар рәвешендә РО МО реестрларын тапшыра.

3. Министрлык, РО МО реестрларын алганнан соң 10 календарь көне эчендә, РО МО реестрларындагы мәгълүматларның шәһәр округлары бюджетларын үтәү турында хисаплар мәгълүматларына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тупланма бюджетларын үтәү турында хисаплар мәгълүматларына туры килүен, шулай ук РО МО реестрларының дөрес тутырылу-тутырылмавын тикшерә.

4. Министрлык, бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән тикшерү йомгаклары буенча кимчелекләр ачыкланганда, РО МО реестрларын финанс органнарына эшләп җиткерүгә кире кайтара.

5. Финанс органнары эшләп җиткерелгән РО МО реестрларын, алар финанс органына алынганнан соң 2 календарь көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән таләпләрне үтәү нигезендә, Министрлыкка кабат тапшыра.

6. Финанс органнары РО МО реестрларындагы мәгълүматларның тулылыгына, үз вакытында тапшырылуына һәм дөреслегенә җавап бирә.